Татарстан РеспубликасыАпас муниципаль районы
Морзалар урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Кичер кайта алмавымны...
(әдәби-музыкаль кичә)




«Туган якны өйрәнү» музее активы.
Җитәкче: Бадрутдинов Р.Р.

2015 ел
Ябалак авылы

Кичер кайта алмавымны...
(әдәби-музыкаль кичә сценариясе)

Бик борынгы заманнардан ук Ватан сакчысы булу дәрәҗәле, абруйлы һөнәрләрдән саналган. Соңгы елларда ил сакчысы булып хезмәт итәргә теләүче яшьтәшләребезнең саны кимегәннән – кими, армиягә һәм хәрби хезмәткәрләргә ихтирам да элеккечә югары түгел. Кораллы Көчләргә һәм хәрби хезмәткә мондый мөнәсәбәтнең сәбәпләре мәгълүм: Әфганстан һәм Чечня җирендәге сугыш хәрәкәтләре, хәрби промышленностьны үстерүгә тиешле игътибар итмәү, хәрбиләрнең хезмәтен тиешенчә бәяләмәү, шулай ук РФ Кораллы Көчләре сафларында уставка каршы гамәлләрнең еш булып торуының вакытлы матбугатта чагылышы...

Әлеге очрашу хәрби хемәт кешеләрен олылау, армиядә һәлак булган егеләребезне искә алу, балаларда, яшьүсмерләрдә гражданлык хисләре тәрбияләү максатыннан уздырыла.

Быел 15 февраль көнне Әфган сугышы тукталуга 21 ел тулды. Районыбызда шушы уңайдан 15 февраль көнне Әфганчылар белән очрашу булып узды. Менә бездә үз чиратыбызда алар белән очрашуны, күрешүне максат итеп куйдык.

Әфганчылар... аларны чит җирләрдә, таш-кыялар арасында кичергән авырлыклар берләштергән, яшәүнең мәгънәсен, тормышның кыйммәтен аңларга өйрәткән. Туган якларга тыныч тормышка әйләнеп кайткач та бергә, бердәм булырга сүз куешкан егетләр вәгъдәләрен бүген дә истән чыгармыйлар. Очрашалар, күрешәләр, яшь буынга хәрби – патриотик тәрбия бирүнең яңа алымнарын эзлиләр. Сугыш ветераннарыннан кала, бүгенге көндә әфганчылар, яшьләргә үрнәк, өлге, киңәшче, тәрбия чыганагы булып тора. Күпне күргән егетләрнең һәр сүзе үтемле кирәкле.

Әфганстан... Чечня... күпме яшь йөрәкләрне яралаган, гаиләләргә төзәлмәслек җәрәхәт алып килгән, күз яшьләренә дучар иткән бу сүз һаман да телләрдән төшми, сугыш сөреме ир-атларыбызны тормышта да авырулары белән газаплап тора.

Әфган вакыйгаларында районыбыздан 81 ир-егет катнаша. Аларның һәрберсенең характерында, сәламәтлегендә бу көннәр үз эзен калдырды.

Кичә барышы.

Магнитофон язмасында сугыш хәләтен чагылдырган тавышлар яңгырый. Хәрби кием кигән ике укучы симфоник музыка барышында Р.Фәйзуллинның “Кичер кайта алмавымны” шигыреннән өзек укый.

1 нче укучы
Кичер, әнкәй, кичер
Кайта алмавымны!
Чит ил туфрагында
Ятып калганымны.
2 нче укучы
Язмышымны белми
Озак көткәнсеңдер
“Кайтмый калмас ул,”- дип
Өмет иткәнсеңдер.
1 нче укучы
Барысын илгә бирдем,
Ни бар көчем булды.
Һәлак булуым да
Халкым өчен булды.
2 нче укучы
Кичер, әнкәй, кичер
Кайта алмавымны!
Чит ил туфрагында
Ятып калганымны.

Алып баручы кичәдә катнашучыларны сәламли, кунаклар белән таныштыра. (Кунаклар: әфганчы егетләр, һәлак булган сугышчыларның әниләре, әтиләре, туганнары).

Алып баручы. Сез “Хәтер” китабы белән таныш инде. Бүген “Әфган сугышы корбаннарының Хәтер китабы” битләренә күз салырбыз. Ул Әфганстанда 10 ел буе дәвам иткән сугышта һәлак булган, хәрби бурычын намус белән үтәгән, моның өчен гомерен дә кызганмаган батырлар истәлегенә багышлана.

Ә хәзер сүзне “Туган як музее” мөдире Галимҗанова Илгизә апага бирәбез. Хәтер китабын күрсәтеп сөйләп китә: Югары Биябашы авылы егетләре Фәйзуллин Тәлгать һәм Михеев Николайлар турында.

Алар хөрмәтенә ... җыр башкара. “Әнием дисбесе” һәм

“Мәхәббәт җимешләре” дигәнне.
Алып баручы. Һәркемгә мәгълүм, сугыш корбаннарсыз булмый. Яу булып үткән урыннарда туганнар каберлекләре дә, аерым каберләр дә кала килгән.
3 нче укучы
Кайтарыма бер ай калганда
Дошман тубы өзде гомерне.
Кичерегез, газиз туганнарым,
Әйталмадым соңгы гозерне.
Әфганстан, ташлы туфрагыңа
Ятып калды тәнем мәңгегә.
Мәңгелеккә ятып калганыма
Гаепле соң хәзер кем генә?
Әнкәемнең ап-ак чәчләренә
Гаепле соң хәзер кем генә?
4 нче укучы
Түз, күз нурым, тиздән күрешербез, дип
Язган идең соңгы хатыңда.
Хуш, әнкәем, сине күрә алмыйча
Ятып калдым таулар артында,
Ятып калдым таулар артында.
(Роберт Шәймәрданов)
Җыр.
Алып баручы. Сугышлар бүген дә дәвам итә. Күпме яп-яшь егет Чечня җирендә ятып калды. Меңләгән ата-ана газизулларын югалтты. Якты дөньяның һәр таңына сөенеп яшәргә дә яшәргә тиеш булган күпме сөлектәй егетне сугыш алып китте... Түбән Биябашы авылы егете Вәлиев Рәмис турында сөйләп китмичә мөмкин түгел. (аерым биттә бирелә).
5 нче укучы
Мин зиратка керәм,
Алда каберлекләр...
Берәү, икәү, өчәү, егерме...
Тукта, кызыл йолдыз куелганы
Содат каберлеге түгелме?

Яшь агачлар үсә өстендә,
Ак чәчәкле венок куелган.
Ә исеме җуелмаслык итеп
Мәрмәр ташка тирән уелган.
Якынрак килеп укыйм,
Дулкынлана минем йөрәгем.
Мондый тыныч көндә ничек үлде икән?-
Мин ни уйларга да белмәдем.

Алып баручы. Ә хәзер сезнең хөрмәткә “Татар халык биюе” карап китегез.

Алып баручы. Еллар үтү белән күп вакыйгалар хәтердән җуела. Әмма без тарихтагы кайгылы көннәрне онытырга тиеш түгелбез. Гомеренең иң матур вакытында һәлак булган егетләребезнең исемен, алар турындагы мәгълүматны җентекләп укысак, туган илгә беркайчан да әйләнеп кайтмаячак якташларыбызга карата сугыш һәм әрнү хисе түгел, бәлки аларның “намус” һәм “хәрби бурыч” төшенчәләренең тормышыннан да өстенрәк куйганнары өчен горурлану хисе кичерәбез.

Солдат сугышны сайламый. Ул сугышны игълан да итми. Ул бары тик, биргән антына һәм хәрби бурычына тугырыклы булып халык һәм Ватан исеменнән бирелгән боерыкны гына үти.

Аның каһарманлыгы, батырлыгы, Ватанга ихтирамыһәм мәхәббәте нәкъ менә шунда күренә.

Егет. 1979 елның 27 декабрендә Советлар Союзы хөкүмәте карары нигезендә Әфганстан территориясенә чикләнмәгән күләмдә гаскәрләр кертелде.

Сугыш... Ун ел буе дәвам иткән сугыш...

Күпме кешеләрнең гомерен өзгән каһәр суккан сугыш...

Кыз. Безнең республика территориясеннән чакырылган 9 меңнән артык солдат һәм офицер әфган җирендәге сугыш хәрәкәтләрендә катнашты. Күп кенә каһарман һәм батыр егетләр бүләкләргә лаек булды. 250 сугышчы – төрле орденнар, 1415 кеше медальләр белән бүләкләнде.

Әфган вакыйгаларыннан соң ике дистәдән артык ел үтеп китте. Бу вакыт эчендә төрле үзгәрешләр булды. Ләкин ун ел буе дәвам

иткән сугыш нәтиҗәсендә һәлак булган, контузия, җәрәхәт, авырулардан үлгән, хәбәрсез югалган меңләгән сугышчы һәм хезмәткәрнең исеме хәтердән беркайчан да җуелмас.

Егет. Районыбыз бүген нур эчендә -
Бөркетләрен җыйган үзенә...
Солдат биштәрләре асып иңенә,
Алар китә Ватан чигенә.

Малайлар башкаруында "Солдатлар" җыры башкарыла
(Р.Әхмәтҗанов сүзләре, Ф.Әхмәдиев көе. Бер төркем егетләр җырлап чыгып китә, кызлар кулъяулык болгый-болгый озатып кала).

Кыз. Бер кайтырбыз дип киткән юлдан
Күпләр илгә кире кайтмады.
Алар өчен бары җилләр генә
Ачып-ябып йөрде капканы.

Алып баручы. - Әйе, уллары цинк табутларга "төренеп" кайтса да, әти -әниләре күңелләре белән гомер буена газизләрен олы юлга карап, күзләрен алмыйча көтә. Юлда чит-ят кеше күрсә дә, аларга газизләреннән хәбәр киләдер кебек тоела. Әфган сугышында һәлак булганнарны якыннары, туганнары, дуслары олылап һәрдаим искә ала. Аларның кулларында бары тик улларының балачак, яшьлек фотолары белән беррәттән әнкәйләргә мәхәббәт белән сугарылган солдат хатлары.

Алып баучы. Ә хәзер әфган сугышында һәм Чечня сугышында һәлак булган егетләребезнең әниләренә, сеңелләренә сүз бирелә.

Алып баручы

Тын кал, иптәш!
Зур сынаулы еллар килгән чакта
Беленә икән кемнең – кемлеге
Бер минутлык тынлык белән
Искә алык бүген без сезне.
(1 минут тынлык).

Кыз. Югалтулар алып килде сугыш,
Күпме дуслар кайтмый калдылар.
Шул дусларның йокыларын саклап,
Ак каеннар моңсу шаулыйлар.

Алып баручы. Ә хәзер  җыр башкарыла. (“Кичер, әнкәй, кайта алмавымы” җыры. Р.Фәйзуллин сүзләре, Л. Батыр-Болгари көе.).
Алып баручы. Залда утыручы егетләргә сораулар бирә.

Дөньяда нинди көч гап-гади кешеләрне батырлыкка илтте икән?

Батырлыкларның бөеклеге нәрсәдә?

Сугыш кырында үлем белән күзгә - күз очрашканда калтырап төшмәс өчен, палач балтасы астына баш салганда елмаер өчен нинди көч кирәк?

Мондый көчле рухлы егетләрне гап-гади әниләр ничек тәрбияләп үстерде икән?

Кыз. Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Әмма канкойгыч сугышлар турында онытырга беребезнең дә хакы юк!

Егет. Изге җиребезне илбасарлардан саклап калган, аның иминлеге өчен гомерен дә кызганмаган Ватан сугышы каһарманнары, Әфганстан, Чечня җирләрендә сугыш кырында һәлак булган, хәбәрсез югалган якташларыбыз, армия сафларында хезмәт иткәндә яшь гомерләре вакытсыз өзелгән Татарстан улларының якты истәлеге алдында баш иябез!

Кыз. Замандашлар! Сезгә мөрәҗәгать итәбез! Сезгә бә мөрәҗәгать итәбез, киләчәк буыннар! Азатлык өчен көрәштә гомерләре өзелгән батырларның истәлеген кадерләп саклыйк. Аларның исеме, онытылмас эшләре, якты маяк булып, буыннардан буыннарга күчсен.

Егет. Каберләргә,  һәйкәлләргә сукмак өзелмәсен. Тыныч йоклагыз батырлар.

Татар халык биюе.

Очрашуга килүчеләрне чәй өстәле янына алып керәбез һәм кечкенә генә бүләкләр бирәбез. Истәлеккә фотога төшәбез.

***Вәлиев Рәмис Мөдәрис улы.***

Апас районының Морзалар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Казанның 123 нче лицеенда электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы һөнәрен алган Рәмис армиягә 1999 елның ноябрендә киткән иде. Чиләбе өлкәсенә барып урнашкач туганнары җиңел сулап куйды. Аннары Рәмисне Екатеринбургка күчерәләр һәм медицина ярдәме күрсәтү курсларында укыталар. 2000 елның сентябрь аенда командирлары Чечняга бару-бармау теләген сорашкач, ул шунда китәргә ризалыгын белдерә. Рәмиснең бу хәбәрен алгач туганнарының, әнисенең күңелләренә шом төшә. Ләкин Мөдәррис абыйга Рәмисне хәрби киемнән күрергә язмаган икән. Ул аның кайтканын көтеп өлгерә алмыйча дөнья куйды. Рәмис аны күмәргә кайтып өлгермәде, каберен кочаклап елап кына китте. Нечкә күңелле иде Рәмис. Менә Рәмис хезмәтен бетереп кайта-кайта, дип көткәндә Рәмис үлде дигән хәбәр килә Ростов Дон шәһәреннән.

2001 елның 16 августы Түбән Биябашы авылы тарихына кайгылы көн булып кереп калыр. Озатырга килгән халыкның исәбенә чыгарлык түгел иде. Район хакимияте башлыгы Азат абый Хәнифәтуллин бәгерьләргә үтеп кererлек итеп хушлашу сүзе сөйләде: “Ходай калган балаларыгызга шушы улыгызның гомерен бирсә иде,” –диде. Аңа 20 июньдә 22 яшь тулган гына иде. Ә авыр хәсрәт, аңлатып булмаслык ачы сагыш җир өстендә калды. Елады халык, әрнеп, өзгәләнеп, тыела алмыйча елады.

Ә Нәҗия апа авыр сулап:

- Рәхмәт яусын инде, хакимият башлыгы Азат Хәнифәтуллин да, совхоз рәисе Таһир Ибраһимов та бик булыштылар, кайгыбызны уртаклаштылар, рәхмәт аларга. Минем хасрәтне йөрәкләренә якын алып улымны озатырга килгән халыкка да рәхмәт яусын. Инде мондый табутларны, мондый кайгыларны беркемгә дә күрергә язмасын иде”- диде.

Бу язманы авылдашы,сабакташы, журналист Назиля Сафиуллина язып чыккан иде “Татарстан яшьләре” газетасына. (№ 28 – 4 сентябрь 2001 ел).

Ә инде бу шигъри юлларны дусты Саттаров Айрат язды (Рәмиснең

якты истәлеге хөрмәтенә)
Язмышлардан юктыр узмышлар.
Олы юлдан озатып калдың, әнкәй,
Кайтыр улым, диеп көткәнсең.
Син бәхетле мизгелләрне уйлап,

Очрашулар өмет иткәнсең.
Кайталмадым, әнкәй, туган-үскән якка,
Салдым сиңа борчу-сагышлар.
Өзгәләнде үзәк, әрнеп янды йөрәк,

Нигә ачы булды язмышлар.
Моңсу күзләр килеп ишек каккач,
Син язлардан өмет өзгәнсең.
Кайгы – хәсрәт безнең өйгә кергәч,

Әнкәй бәгърем, ничек түзгәнсең.
Ямьле язлар җиткәч,туган якта,
Күмеләдер бакча гөлләргә.
Язмышлардан узмыш юк шул, диләр,
Яшьли кердем гүрләргә. “Йолдыз” газетасы №9. 30.01.2002 ел).
Вәлиев Рәмис Мөдәрис улы.
20 июнь1979 – 5 июль 2001.
2001 ел 16 августта
Т.Биябашта күмелде.
Чечня – Шалида һәлак
була.Фотокарточканың
икенче ягында Рәмиснең
үз кулы белән:
“Истәлеккә - мәңгегә.
Карап искә алыгыз,
Искә алып карагыз” дип
язылган.



***Гатауллин Дамир Рөстәм улы.***



1981 елның 6 нчы февралендә туа. 2000 елның августында Чечнядагы Төньяк Кавказ регионына, берләшкән кораллы көчләр войскасына шофер итеп билгелиләр. Ул анда 2001 елның 13 февраленә кадәр хезмәт итә. Дамир 177 көн буена барган сугышларда катнаша. Шуннан соң аны 14 май 2002 ел № 498 Президент указы нигезендә буенча “Георгий Жуков” медале белән бүләклиләр. Десантный войскода хезмәт итә. Командирларыннан бик күп рәхмәт хатлары ала 2000 елның 17 мартында беренче тапкыр парашюттан сикерә ул.

Дамир Флера апа белән Рөстәм абыйның төпчек, бишенче уллары була. Ләкин бик кызганыч, Дамир шушы сугышлардан йөрәге авыртып кайта, тыныч көннәрдә озак яшәү язмаган икән аңа.



## МИХЕЕВ
## Николай Васильевич

Родился 21.5.65. Татарстан, Апастовский р-н, д.Верхний Биябаш. Русский.

Место работы - совхоз «Апастовский».

Моб. Апастовским РВК 1.10.83.

В ДРА с 2.1984.

Рядовой, стрелок в/ч пп 19920.

29.12.84 погиб при исполнении служебных обязанностей.

Награжден орденом Красной Звезды и медалью «Воину-интернационалисту» (посмертно).

Зах. в д.Верхние Биябаши.

В Мурзинской средней школе его имя присвоено пионерскому отряду.

## МИХЕЕВ
## Николай Васильевич

21.5.65 тә Татарстаның Апас р-оны Югары Биябаш авылында туа. Рус.

«Апас» совхозында эшли.

Кораллы Көчләргә 1.10.83 тә Апас РХК тарафыннан алына.

Әфганстанда 1984 нең февраленнән.

Рядовой, укчы.

29.12.84 тә, хезмәт вазыйфаларын башкарганда, һәлак була.

Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә (үлгәннән соң).

Югары Биябаш авылында җирләнгән.

Морзалар урта мәктәбендә пионер отрядына аның исеме бирелгән.

### Стихотворение Николая

"Поздравляю с Новым годом, мама!
И желаю долгих лет.
Написал тебе стихотворение,
Хорошо, а может быть и нет.
В нем хочу я выразить признанье
За заботу, ласку и тепло.
За любовь, за то, что воспитала,
Ведь, наверно, было нелегко.
Здесь, на службе, понял я немало,
Что любимей всех, тебя на свете нет.
Моя родная мама, тебе и папе,
всем родным
Шлю солдатский добрый свой привет.
По ночам я часто вспоминаю
Теплоту твоих ласковых рук.
Для меня ты сделала немало,
Желаю счастливых долгих лет.
Только все не выскажешь в стихах,
Вот вернусь, родная моя мама,
Все скажу не в письмах, а в словах..."

### Ответ матери:

Не суждено было живым вернуться,
Матери сказать, о чем мечтал.
На втором году армейской службы
Жизнь в девятнадцать лет забрал
Афганистан.
В цинковом гробу вернули сына
Матери, отцу, что так устали ждать.
В трауре стекло на крыше гроба
И лица родного не видать.
А хоть матери, как прежде,
До него дотронуться рукой,
Приласкать, погладить, приголубить,
В очи заглянуть, сказать:
- Сынок, родной!
Обещал ты, что вернешься скоро,
И работать будешь на селе.
Ни любовь свою к земле, ни руки,
А всего пожертвовал земле.
Пусть земля родная мягче пуха будет,
Спи, сынок, как в детстве дома спал.
В нашей памяти останешься ты юным,
Как пошел служить в Афганистан...

**Орден Красной Звезды**





## ФАЙЗУЛЛИН
### Талгат Нариманович

Родился 27.4.62. Татарстан, Апастовский р-н, д.Верхние Биябаши. Татарин. Место работы - колхоз им.Ильича. Моб.Апастовским РВК 25.10.80. В ДРА с 12.1980. Рядовой, водитель в/ч пп 46357. 2.3.81 умер от ран в военном госпитале № 340 г.Ташкент.

Награжден орденом Красной Звезды (посмертно). Зах. в д.Верхние Биябаши.

## ФӘЙЗУЛЛИН
### Тәлгать Нариман улы

27.4.62 дә Татарстанның Апас районы Югары Биябаш авылында туа. Татар. Апас районының Ильич исем. колхозында эшли. Кораллы Көчләргә 25.10.80 дә Апас РХК тарафыннан алына. Әфганстанда 12.1980 нән. Рядовой, йөртүче. 2.3.81 дә Ташкент шәһәренең 340 номерлы хәрби госпиталендә яралардан үлә.

Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә (үлгәннән соң). Югары Биябаш авылында җирләнгән.

Бу шигырьләрем Әфган җирендә гомерлеккә ятып калган яраткан абыем ТӘЛГАТЬ истәлегенә.

Миләүшә

### ЫШАНМЫЙМ

Мин ышанмыйм синең үлемеңә,
Кайтуыңны һаман көтәмен.
Синең киткән юлларыннан, абыем,
Сине искә алып үтәмен.
Синсез булгач, күзләремдә яшьләр,
Күңелемдә сагыш төере.
Йөрәгемдә авыр җәрәхәттән
Кара болытларның өере.

### ӘФГАНСТАН

Әфганстан! Күпме авыр хәсрәт,
Күпме күз яше син китердең.
Бер гөнаһсыз күпме нарасыйны
Ни өчен соң ятим иттердең?
Әфганстан! Хәтта сүзен ишетү
Йөрәкләрне үтә әрнетеп.
Күпме бала күзгә карап тора
Аталарча җылы наз көтеп.
Әфганстан! Кемгә кирәк булды?
Кемгә кирәк иде бу сугыш?!
Хәтта «әни» диеп әйтә алмыйча
Өзелде бит меңнәрчә сулыш.

### НИГӘ, ЯЗМЫШ, НИГӘ?

Нигә, язмыш, нигә болай ачы булдың?
Улымны бик яшьли гүргә кертеп куйдың.
Җылы якка кошлар киттеләр тезелеп
Көттек кайтуыңны, абый, без өзелеп.
Син киткән юллардан күзне һич алмадык.
Үзеңә мәгълүм бит кайгыга салганың.
Бар дөнья караңгы син булмагач янда.
Үзең үлсәң дә син калачаксың җанда.
Очрашмабыз, кабат еллар синсез үтә.
Йөрәк әле һаман, абыем, сине көтә.

### ҖЫРГА ӘЙЛӘНГӘН ГОМЕР

Армиягә китте егет, җырга һәвәс иде.
Киткән чакта ул елмаеп:
«Яз кайтырмын», — диде.
Туган якка көтеп алган язлар килде кабат.
Язлар килде, әмма ләкин кайталмады солдат.
Китүенә 5 ай тулгач өзелде гомере.
Егет үлде, ана өчен тик ул һаман тере.
Бу яшь егет искә төшә һәр көн туган саен.
Аның җырын көйли сыман бакчадагы каен.

### КАЙТА АЛМАДЫҢ

Кайтыр диеп көтте газиз анаң,
Кайтыр юлдан күзен алмады.
Ничә еллар буе көтте сине
Тик өметен һаман өзмәде.
Кайталмадың туган җирләреңә,
Чит җирләрдә гомерең өзелде.
Безнең янга кабат кайтмасыңны
Бер ходайдан башка кем белде?!
Абый, синең каберең өстендә
Лилияләр чәчәк аталар.
Сине кабат күреп китү өчен
Туганнарың һәрчак кайталар.
Кабереңә синең таш куелган,
Исем-фамилияң уелган.
Бик-бик яшьли, 19 яшь тулмас,
Гүр иясе булды диелгән.
Кабереңдә үскән ак каенга
Сандугачлар куныл сайрыйдыр.
Бигрәк яшьли дошман кулларыннан
Вафат булды егет, диептер.

Военный билет Талгата



умер 2.3.81

ВОЕННЫЙ БИЛЕТ
НП № 7218013

Фамилия Файзуллин
Имя Талгат
Отчество Нариманович
Число, месяц и год рождения 27.04.1962.
Личная подпись владельца
Выдан Апастовским районным военным комиссариатом ТАССР области (республики)
25 октября 19.. г.
военный комиссар
м. п.
Шарипов
(личная подпись)

НП № 7218013 1

I. Общие сведения

1. Место рождения д. В. Биябаши Апастовского района ТАССР
2. Национальность татарин
3. Партийность (с какого года)
4. Состоит ли в ВЛКСМ (с какого года)
5. Образование
6. Основная гражданская специальность водитель
7. Семейное положение холост

# Воины—интернационалисты



***Ахтареев Марат Ринатович***

**Родился 3.07.1966 года.**
**Выпускник Мурзинской средней школы.**
**Призван в армию 1985 году.**
**Принимал участие в боевых действиях на территории Афганистана.**
**В настоящее время работает главным инженером ООО СХП «Ибрагимов и К»**



***Биккулов Ильдус Ирегович***

**Родился 3.07.1967 года.**
**Выпускник Мурзинской средней школы.**
**Призван в армию 1986 году.**
**Принимал участие в боевых действиях на территории Афганистана.**
**В настоящее время является индивидуальным предпринимателем.**



***Загиев Рашит Абдуллович***

**Родился 21.11.1960 года.
Выпускник Мурзинской средней школы.
Призван в армию 1978 году. Принимал участие в боевых действиях на территории Афганистана. Награжден медалью «За Отвагу**



***Камалиев Ильшат Фагимович***

**Родился 26.07.1967 года. Выпускник Мурзинской средней школы. Призван в армию 1985 году. Принимал участие в боевых действиях на территории Афганистана.
В настоящее время работает в ОАО «ХПП Каратунское» главным инженером.
Награжден медалями «От благодарного афганского народа», «Воину-интернационалисту».**



***Сайфуллин Ирек Халилович***

**Родился 22.07.1966 года.**
**Выпускник Мурзинской средней школы. Призван в армию 1984 году. Принимал участие в боевых действиях на территории Афганистана.**
**В настоящее время работает сварщиком.**





***Сунгатуллин Ильдус Назымович***

**Родился 16.02.1976 года.**
**Выпускник Мурзинской средней школы 1993 года. Призван в армию в декабре 1994 года.**
**Принимал участие в боевых действиях на территории Чеченской Республики.**
**В настоящее время работает учителем физкультуры и ОБЖ МОУ «Давликеевская основная общеобразовательная школа».**



***Сунгатуллин Фирдус Назымович***

**Родился 16.02.1976 года.**
**Выпускник Мурзинской средней школы 1993 года. Призван в армию в декабре 1994 года. Принимал участие в боевых действиях на территории Чеченской Республики.**
**В настоящее время работает учителем физкультуры МОУ «Мурзинская средняя общеобразовательная школа».**



***Гайнутдинов Ильдар Рашидович***

**Родился 10.04.1975 года. Выпускник Мурзинской средней школы 1992 года. Призван в армию 1993 году. Принимал участие в боевых действиях на территории Чеченской Республики.**
**Награжден Высшим знаком отличия МЧС России «Оранжевый берет».**
**В настоящее время работает в ООО «Жилстрой».**



***Загрутдинов Рустам Тафкилович***

**Родился 20.11.1975 года. Выпускник Мурзинской средней школы 1993 года. Призван в армию 1993 году. Принимал участие в боевых действиях на территории Чеченской Республики.**
**В настоящее время работает механизатором**
**ООО СХП «Ибрагимов и К».**

Кулланылган материаллар:

1. КНИГА ПАМЯТИ жертв войны в Афганистане,
Әфганстан сугышы корбаннарының ХӘТЕР КИТАБЫ,
Республика Татарстан Казань
Татарстан Республикасы Казан, 1999
2. “Татарстан яшьләре” газетасы, № 28 – 4 сентябрь 2001 ел.
3. Йолдыз № 9 - 30 январь 2002 ел.

Морзалар урта гомуми белем бирү мәктәбе
«Туган якны өйрәнү» музее активы
Җитәкче: Бадрутдинов Р.Р.